ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАВЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Нагорная, д.70, с. Тавели,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422160

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАУИЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Таү өсте урамы, 70 йорт, Тауиле авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422160

Тел. (факс): (85563) 2-67-25 e-mail: Tavel.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление Карар

“27” ноября 2019 г. № 20

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Тауиле авыл җирлегендә гражданнарныңүзара салым акчаларын
җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы « Тауиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Тауиле авыл җирлеге граҗданнарының карарларын тормышка ашыру максатыннан
2019 нчы елның 21 ноябрендә кабул ителгән 1 нче номерлы “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге составына керүче Тауиле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге башкарма комитеты;
2019 нчы елның 22 ноябрендә кабул ителгән 2 нче номерлы “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге составына керүче Нагашево авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге башкарма комитеты;
2019 нчы елның 27 ноябрендә кабул ителгән 3 нче номерлы “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге составына керүче Чаксы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге башкарма комитеты;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге башкарма комитеты;

К а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Тауиле авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Тауиле авыл җирлеге Советы рәисе /В.И.Иванов/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы
Тауиле авыл җирлеге
Башкарма комитетының
27.11 2019 ел, 20 санлы
карарына 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Тауиле авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Тауиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2020 елның 26 мартына кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала

3. Җитди сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга гариза нигезендә, бер айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, җиткерелә, шулай ук шәхсән кул куйдыртып яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җибәрелә ала.

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки

https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Тауиле авыл җирлеге
Башкарма комитетының 27.11. 2019 ел,
20 санлы карарына 2 нче кушымта

Тауиле авыл җирлеге
(*муниципаль берәмлек исеме)*
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
__________________________________________________________________________

Адрес: ____________________________________________________________
Мамадыш муниципаль районы ___________ авыл җирлегенең __________ авылында гражданнар җыены карары нигезендә 2020 нче елда үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча Сезгә 2020 елда халык җыены чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр ______ сум күләмендә түләүне, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: __________________________________________________
Кабул итүче як банкы БИК _____________________________________
Сч. № _________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № _________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП ______________________________________
КБК _______________ ОКАТО __________________
Түләүнең билгеләнеше
Гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче _________________ ____________________________________П. У.
(имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - -

_______________________________________________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*
________________ сум күләмендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _________________

Түләүченең Ф.И.Ә.и. _______________________________________________________
Адрес: __________________________________________________________
«__» _______________ 20__ г. ___________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)____________________*
*авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.*